КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 5 май г.Казань № 573

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын даими нигездә билгән затлар вәкаләтләрен үтәүгә бәйле тәэмин ителә торган транспорт хезмәте күрсәтү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 5 май, 282 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын даими нигездә билгән затлар вәкаләтләрен үтәүгә бәйле тәэмин ителә торган транспорт хезмәте күрсәтү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын даими нигездә билгән затлар вәкаләтләрен үтәүгә бәйле тәэмин ителә торган транспорт хезмәте күрсәтү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 5 май, 282 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын даими нигездә билгән затлар вәкаләтләрен үтәүгә бәйле тәэмин ителә торган транспорт хезмәте күрсәтү тәртибенә, 6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы Рәисе һәм (яки) Татарстан Республикасы Премьер-министры тарафыннан үткәрелә торган чараларны, Татарстан Республикасы Рәисе һәм (яки) Татарстан Республикасы Премьер-министры йөкләмәсе буенча башка чараларны әзерләгән һәм аларда катнашкан очракларда;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин